Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



№1
Сентябрь 2017 г.

## Счастье только знающим дано!

***Первое сентября считается особым днём. Его называют Днём знаний. Именно в этот день тысячи школьников сели за парты - начался процесс постижения знаний, получения новой информации, которая станет надежным попутчиком в жизни.***

В этот день в нашей школе прошла торжественная линейка, посвящённая Дню знаний. В этом году порог школы переступило 85 счастливых и нарядных первоклассников. Они порадовали всех нас веселыми стихами и песнями.

На линейке присутствовал и Глава администрации Арского муниципального района Ильшат Габделфартович Нуриев. Он от всего сердца поздравил нас с началом нового учебного года и пожелал успехов, терпения и крепкого здоровья. Далее во всех классах прошли традиционные уроки Мира.

Ильшат Габделфартович на примере своей жизни доказал, что путь большому начинается с малого. В школе он был отличником учебы, успешно окончил Казанский сельскохозяйственный институт, Московскую коммерческую академию. Начал трудовую деятельность в 16 лет, работая простым трактористом. Отдав свой долг Отчизне, стал начальником колбасно-




## Татар телен өйрәнәбезме?

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы социаль челтәрләрдә татар телен өйрәнүдән баш тартуга чакыру сәбәпле аңлатма бирде. Россия Федерациясе Конституциясе Рәсәй составына кергән республикаларга дәүләт телләрен билгеләргә хокук бирә. Татарстан Республикасы законы тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт теле сыйфатында рус теле белән беррәттән татар теле дә билгеләнгән.

Федераль законнар тарафыннан татар телен гомуми белем бирү тармагында Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак өйрәнү каралган.

Россия Федерациясе Конституция суды карары белән татар теле Татарстанның барлык гомумбелем оешмаларында мәҗбүри предмет буларак өйрәнелергә тиеш. Шул рәвешле, социаль челтәрләрдәге татар телен өйрәнүдән баш тартуга чакырулар гамәлдәге кануннарга каршы килә һәм ата-аналарга дөрес булмаган мәгълүмат җиткерелә.

### Интересно знать!

- Слово **«школа»** имеет греческое происхождение и означает «досуг».
- Не в каждой стране мира учеба начинается с **первого сентября**.
- **Японские школы** не имеют столовых.
- В **Норвегии** ученикам до 8-го класса оценки не ставятся.
- В **Бангладеше** есть школа в лодке.
- **Китай** славится «пещерной» школой.
- В **южных странах** школы не имеют сте-

### В этом выпуске:

Вечная память М.Лотфуллину! 2
Без - Тукай оныклары! 2
Олыласаң олыны, олыларлар 3
Өлкәннәр безнең янәшәдә 3
Күпне күргән, күпне кичергән... 4
Сез - минем горурлыгым! 4
Лента новостей 4

- Не забывайте, что только образование открывает широкую дорогу в будущее и является надежной базой для успешной жизни! - отметил Ильшат Габделфартович.

Далее директор школы Гульназ Галиевна Гиниатуллина рассказала о наших достижениях:

- В прошлом учебном году мы добились многого. Это два призера и один победитель республиканских олимпиад, это стобальница по русскому языку, ученице нашей школы Саляховой Фанузе заложили звезду на аллее звезд, наши вокалистки Никитина Зарина и дуэт РозалИс достойно представляют нашу школу во многих престижных республиканских конкурсах. Изюминкой нашей школы являются юнармейцы, ансамбль барабанщиц «Ритм». И, конечно же, наши спортивные достижения, которые отражаются в постоянно пополняющемся кубками стеллаже! А также множество мероприятий как школьного, районного, так и республиканского уровней, которые мы провели в стенах нашей школы. Будем надеяться, что в этом году их количество возрастет в два раза!

*Рузаль Шарипов, 8Б класс*

# Вечная память Марату Лотфуллину!

***11 сентября в Арской СОШ №2 прошел Мемориал памяти Марата Лотфуллина, воина-афганца, выпускника нашей школы, погибшего во время исполнения интернационального долга и посмертно награжденного Орденом Красной Звезды. В рамках мероприятия отряд юнармейцев нашей школы навестил его могилу на татарском кладбище города Арск, где ребята возложили венки к могиле воина и услышали рассказ о его судьбе.***



Он родился 21 апреля 1968г. года в городе Норильске Красноярского края. В школе он отличался от других. Его умные ответы порой удивляли даже учителей. Отличительной чертой Марата была неустанная тяга к труду. Всегда вдохновенно, с настроением работал Марат на поле.

Своей скромностью, простотой он завоевал уважение товарищей, учителей, соседей. Одним из первых его приняли в ряды комсомол. Марат увлекался чтением. Больше всего читал военные книги, любил увлекательно рассказывать о прочитанном. Ему легко давались география, история, биология. Он красиво говорил на родном языке. Настал выпускной класс. Марат еще не знал, что через небольшой промежуток времени будут чтить его память минутой молчания.

Впереди—экзамены в Казанский строительный институт, учёба, сессия, призыв в ряды Советской Армии... Служил Марат в танковой роте. Полк находился в пригороде города Газни, в древней столице Афганистана. 8 апреля оборвалась его жизнь. Он пролил кровь, но честно выполнил присягу. Его мама в один день постарела, папа не видел земли под ногами. 7 апреля 1989 года в нашей школе открылась мемориальная доска, увековечивающая память выпускника школы, бывшего война- интернационалиста.

*Алия Хабирова, 8Б класс*

# Без - Тукай оныклары

***Быел мин «Без-Тукай оныклары» исемле чатырлы аланда ял иттем. Ул 8-14 июль көннәрендә Арча районының Кырлай авылында узды. Бирегә Татарстан районыннан, шулай ук Удмуртия, Башкортстан, Мари Иле республикаларыннан, Оренбург, Әстерхан, Киров өлкәсеннән, Казахстаннан 300 бала җыелган идек.***

Лагерьны оештыручылар безгә бик кызыклы программа әзерләгәннәр. Шагыйрь Рифат Җамал, драматург Гафур Каюмов, язучы Гүзәл Шакирова, Казан арты этнография музее директоры урынбасары Шәфигулла Гарипов, Татарстанның атказанган укытучычы Фәргать Зыятов кебек күренекле шәхесләр, “Ялкын” журналы редакциясе хезмәткәрләре, “Яңа гасыр” телерадиокомпаниясе журналисты Фәридә Төхфәтуллина белән очраштык. Тагын без Кушлавыч авылы, Г.Тукай мемориаль музеена экскурсиягә бардык. Шулай ук остаханәләр эшләде. Һәркем үз күңеленә якын булган юнәлештә шөгыльләнә ала иде, мәсәлән, фолклор, бию, музыка уен коралларында уйнау, рәсем ясау, тубәтәй, калфак чигү.

Кыскасы, «Без - Тукай оныклары» лагеры һәркемнең йөркемнең күңеленә хуш килде.

*Алия Хәбирова, 8Б классы*

## Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне!



*Хөрмәтле өлкәннәр!*

Күпме генә бәхет теләсәк тә,
Бик аз булыр кебек тоела.
Нинди генә изгелекләр эшләмәдегез
Кешеләргә гомер буена!
Шуңа Сезне бар да ярaталар,
Күршеләргез йөри кергәләп.
Сәламәтлек, бәхет-шатлык белән
Яшик әле, әйдә, бергәләп!

*Иң изге теләкләр белән*

*мәктәп директоры Гөлназ Гали кызы!*

## Өлкәннәр безнең янәшәдә

***Дөньяда иң якын, иң газиз кешеләр - әти-әниләр, әби-бабайлар. Алар һәрвакыт безнең янда. Әниләр безне йомшак куллары, назлы карашлары һәм киң күңелле булулары белән шатландырса, әти - ләребез көчлелеге, батырлыгы һәм уңганлыгы белән үрнәк булып тора. Әби-бабайлар безне җил-яңгыр тидермичә, кадерләп тәрбияләп үстерә.***

Укучылар! Еш кына бер дә юкка өлкәннәргә каршы сүз әйтелә. Әйтелә дә ... онытыла, ә уйламыйча әйткән шул сүзебез белән без олы кешене ничек рәнҗетүебезне, аның хәтерен калдыруыбызны, аңа ничек кыен булуын белмибез дә. Еллар үтәр. Без дә, сез дә олыгаербыз. Менә шул вакыт барысы да исебезгә төшәр. Сез әле яшь. Соңга калмагыз, үзегезнең начар якларыгызны төзәтергә ашыгыгыз. Әгәр инде хәтер калдырырга өлгергәнсез икән, гафу үтенегез. Үз гаебеңне таный белү – бик кирәкле сыйфат. ...Менә синең әбиең яки бабаң сиңа нинди дидер гозерен әйтә, йомыш куша. Кушканны җи-ренә җиткереп үтә. Үкенү-ләрем кимрәк булсын дисәң, алар исән чакта яхшы укуың, матур яшәвең, игелекле гамәлләр кылуың белән сөендер.

*Рәсимә Ибраева*

## Күпне күргән, күпне кичергән...

***Шайнурова Рауза Шайнур кызы 1931 нче елның 7 февралендә Арча районы Түбән Пошалым авылында дөньяга килә.***

Үз авылларында башлангыч сыйныфларда укый, Аннары Урта Пошалым мәктәбенә йөри башлый. Ләкин Урта Пошалымга артык күп йөрергә туры килми, балалыкларын авыр сугыш еллары ала. Иң беренче әтиләре Шайнурны Суслангерга озаталар. Әтиләре киткәндә 4 бала, әби - бабай ( әби белән бабай үзләренеке түгел, чөнки әтисе Шайнурның да, әнисе Фатыйманың да әти-әниләре, барлык туганнары 1921 нче елгы ачлыкта үлеп бетәләр. Өйләнешкәннән соң, үзләренең балалары булмаган Әсхәдулла белән Гарифәбану исемле игелекле кешеләр яшьләрне йортка керткәннәр)кечкенә генә иске өйдә калалар. Әтиләрен Суслангердан Түбән Тагилга трактор заводына күчерәләр. Суслангерда урман эше эшләгәндә хатыны ике атнага бер булса да сохарилар илтеп тора. Сугыш бетәргә берничә ай калганда ачтан кибеккән әтиләре кайта.

Әтиләрен сугышка алып киткәч, барлык авырлык абыйсы белән кечкенә Рауза өстенә төшә. Ул вакытта Түбән Пошалым "Татарстан№2" колхозы дип атала. Абыйсы да үзе дә мәктәпкә йөрүне оныталар, бригадир ни кушса, шуны эшләргә колхозга чыгалар. Сугыш башланганда бер кайгысыз "сызыкташ" уйнап йөргән бала тормыш арбасына төптән җигелә. Әнисе янында урак ура, көлтә бәйли, көзге уңайга амбарда сушилкага көлтә бирә, кышларын сугыштагы ватандашларга оекбияләй бәйли. Сугыш вакытының авырлыклары беркайчан да онытылмый, балаларны салкыннан саклар өчен өй салырга дип әзерләгән бер өйлек агачны да турап ягарга туры килә аларга.

*(дәвамы 4нче биттә)*



...Әтиләре балаларны сакларга, тундырмаска киңәш итә. “Исән кайта алсам, яңасы булыр,”- ди

Балалар никадәр файда китерә алганнардыр анысын белмим, ләкин алар колхозыннан 3 кенә кешене “За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945гг” дигән Сталин медале белән бүләклиләр. Берсе аның Шайнурова Рауза, икенчесе аның абыйсы – Шайнуров Мәсәгут; өченчесе Рәхимҗанова Әминә апалар була. Концелярия йортына Арчадан вәкил килеп, бик зурлап тапшыралар ул медальне. Бүгенгесе көндә медале дә һәм аның таныклыгы да сакланмаган. Арча архивыннан алган белешмә генә бар.

Сугыш беткәнне тау башында яшел чирәмдә шулай ук кызлар белән уйнап йөргәндә ишетә ул. Бик тә сөенәләр алар, күпме сикергәннәрен, күпме “Ура” кычкырганнарын, кочаклашып берсен-берсе котлауларын әйтә дә алмый.

*Алия Хабирова,8Б классы*

# Сез - минем горурлыгым!

***Лотфуллина Мәһмүзә Хәйретдин кызы бабаемның яу кырында калганын еш искә төшерә һәм миңа да сөйли. Дәү әниемнең әтисе - Җамалиев Хәйретдин 1898 нче елны Арча районы Югары Мәтәскә авылында туган. Сугышта катнашкан бабам белән Хәтирә әбинең берсеннән-берсе кечкенә 6 баласы булган. Аларның иң кечесенә 4, иң олысы - минем дәү әбием Мәһмүзәгә 16 яшь була.***

1941 нче елны 43 яшендә бабамны сугышка алганнар. Башта окоп казытканнар, аннан сугышка алып киткәннәр. Тимер юлда вагон төягән җирдән үк китеп барырга туры килә бабама. Хәйретдин бабам башларын да күтәрми вагон төяүчеләр янына килеп: “Арчалар бармы монда?” дип сорый.

Авылдашы Минзифа апа танып: “Хәйретдин абый, синме бу, берәр хәл булдымы әллә?” дип атылып каршысына чыга. “Әйе шул, авылга кайткач, мине сугышка җибәрәләр дип, Хәтирәгә әйтә алмассың микән? Казанда тукталыш ясыйбыз, бәлки шунда очрашырбыз”, - дигән. Минзифа апа авылга кайтып бөтенесен дә сөйләгән. Өйдә булган барлы-юклы ризыгын алып, бер якын туганы белән Казанга юл тоткан Хәтирә әби.

Мең бәла белән шәһәргә килеп җитеп, тәки тапканнар Хәйретдин бабайны. Ашарына киптергән сохарилар тыгып, елый-елый, сугышка озатып җибәргәннәр.

Китеп байтак вакытлар үткәч, бабаемның хаты килгән. Ул: “Миңа сугышта күбесенчә атта йөрергә туры килә”, - дип язган.

Әтта йөргәннәргә бигрәк хәтәр булган, аларны гел бомбага тотканнар. Бу аның беренче һәм ахыргы хаты булган. Бүтән хатлар килмәгән. Ул шул чактан бирле хәбәрсез югалган дип санала. Аның хәтта кайда күмелгәне дә билгесез. Их, каберенә барып туган нигездән бер уч туфрак булса да салсаң иде ичмасам, дип елаган минутлары булса да, дәү әбием аны гомере буе кайтыр дип көтеп яшәгән.

*Рүзәл Шәрипов, 8Бкласс*



6 сентября обучающиеся 2 смены встретились с ***сотрудниками правоохранительных органов.***

13 сентября учащиеся школы провели уличную акцию ***«Поделись улыкой!»***

15 сентября в нашей школе прошел замечательный праздник, посвященный ***дню Первоклассника.***


Редактор Расима Ханифовна Ибраева

Ответственный секретарь Рузаль Шарипов

Редколлегия Алия Хабирова
Диана Галимова
Ляйсан Шаяхметова
Адиля Киямова


